ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11. 2019 ел Баулы шәһәре № 310

2020 елга Баулы муниципаль
районының гомуми белем
бирү оешмаларының
норматив чыгымнарын
раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 11 декабрендәге 201 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы 2020 елга Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны расларга

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләр тарафыннан расланган, белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2020 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә

белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 2 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән;

әлеге карарның 1 пункты.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе вазифаларын башкаручы И.И. Хөснуллина

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның «___» ___________
кабул ителгән _____
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

2020 елга Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмалары тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 90 980 |
| | авыл җирлеге | 92 342 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 137 238 |
| | авыл җирлеге | 141 713 |